**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ**
**НИЖНЕКАРМАЛКИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

423102, СЕЛО НИЖНЯЯ
КАРМАЛКА, УЛ. ЛЕНИНА, Д.44

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ТҮБӘН КАРМАЛКА АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

423102, ТҮБӘН КАРМАЛКА АВЫЛЫ,
ЛЕНИН УРАМЫ, 44 ЙОРТ

Тел.: (84396)2-39-47 ФАКС: (84396) 2-39-47
Email: Nkar.Cmn2@tatar.ru

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районының**
**Түбән Кармалка авыл җирлеге Советы**
**карары**

**№144** **23.08.2024 ел**

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Түбән Кармалка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 28 декабрендәге Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Түбән Кармалка авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проектын беренче укылышта хупларга һәм ачык тыңлауларга чыгарырга

2. Мәгълүмат стендында урнаштырырга:

- «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы проекты турында» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлеге Советының әлеге карары.
- «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлеге муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлеге Советы карары проекты (1 нче кушымта);
- Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлеге муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проектына гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм фикер алышуда гражданнарның катнашуы тәртибе (2 нче кушымта);
- «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү

турында» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлеге Советы карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү тәртибе (3 нче кушымта).

3. «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлеге Советы карары проекты буенча 2024 елның 16 сентябрендә 14 сәгатьтә киләсе адрес буенча ачык тыңлаулар үткәрергә: 423102, Татарстан Республикасы, Чирмешән районы, Түбән Кармалка авылы, Ленин урамы, 44 нче йорт.

4. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлеге Уставына кергән тәкъдимнәрне, үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

1. Митякин Александр Федорович –Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Түбән Кармалка авыл җирлеге башлыгы.
2. Зайцева Наталья Александровна – Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Түбән Кармалка авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары.
3. Зенина Антонина Дмитриевна – Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Түбән Кармалка авыл җирлеге Башкарма комитетының баш бухгалтеры.

5. Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлеге Советының эшче төркеменә ачык тыңлауларда әйтелгән һәм фикер алышу барышында килгән тәкъдимнәрне исәпкә алып, карар проектын эшләп бетерергә һәм авыл җирлеге Советы сессиясенә карауга кертергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Түбән Кармалка авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе А.Ф. Митякин

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Түбән Кармалка авыл җирлеге
Советының 2024 елның
23 августындагы №144 карарына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Түбән Кармалка авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Түбән Кармалка авыл җирлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 5 статьяның 12 пунктын «Җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләре» яңа редакциядә бәян итәргә: «12) балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшләү һәм гамәлгә ашыру, Җирлектә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруга мониторинг оештыру һәм гамәлгә ашыру.».

1.2. 40 статьяның 1 пунктына: «13) чит ил агенты статусын алу» пунктчасы өстәргә.

1.3. 46 статьяның 1 пунктына: «17) чит ил агенты статусын алу» пунктчасы өстәргә.

1.4. 7 өлешнең 49 статьясында 2 абзацны яңа редакциядә бәян итәргә «-балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыра һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнаша, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау буенча чаралар эшли һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшли һәм гамәлгә ашыра, Җирлектә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруга мониторинг оештыра һәм гамәлгә ашыра».

1.5. 71 статьяны яңа редакциядә бәян итәргә: «71 Статья. Муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе.

1. Кеше һәм гражданның хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Түбән Кармалка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге гамәлгә куйган оешмаларның хокукый статусын билгеләүче муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр рәсми рәвештә халыкка игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

2. Муниципаль норматив хокукый актны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүне рәсми рәвештә халыкка җиткерү булып түбәндәгеләр санала:

1) тулы текстны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында рәсми бастырып чыгару (https://pravo.tatarstan.ru; массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык ЭЛ № ФС77-60244 Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек

буенча федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан 2013 елның 17 декабрендә бирелгән) яисә «Безнең Чирмешән» район газетасында бастырып чыгару, 29.12.2010 елгы ПИ №ТУ16-004876 теркәлү турында таныклык Татарстан Республикасы буенча элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт тарафыннан бирелгән, «Наш Черемшан» район газетасында бастырып чыгару, 30.03.2016 елгы ПИ №ТУ-16-014-76 теркәлү турында таныклык Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан бирелгән, яки «Безнең Чирмешән» («Наш Черемшан») район газетасының рәсми сайтында бастырып чыгару, 16.12.2011 елгы ФС77-47618 теркәлү турында таныклык Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан бирелгән.

2) Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Түбән Кармалка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру (https://cheremshan.tatarstan.ru/sheshminskoe-selskoe-poselenie.htm), ТР,Чирмешән районы, Түбән Кармалка авылы, Ленин ур., 44 йорт адресы буенча мәгълүмат стендларында урнаштыру.

3. Гражданнарның Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталыннан файдалана алуын тәэмин итү өчен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә түбәндәге адреслар буенча тоташтыру пунктлары эшли: Татарстан Республикасы, Чирмешән муниципаль районы, Түбән Кармалка авылы, Ленин урамы 44 йорт. (Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Түбән Кармалка авыл җирлеге Советы һәм Башкарма комитеты), Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайты аша https://pravo.tatarstan.ru/npa_msu/cheremshan.

4. Муниципаль норматив хокукый актлар, җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр, федераль закон белән таратылуы чикләнгән белешмәләр булган муниципаль хокукый актлардан яисә аларның аерым нигезләмәләреннән тыш, аларга кул куелган көннән алып 10 көн эчендә халыкка җиткерелә.

5. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының салымнар һәм җыемнар турындагы норматив хокукый актлары Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә үз көченә керә.

6. Әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелмәгән муниципаль хокукый актлар, әгәр актның үзендә башкасы билгеләнмәгән булса, аларга имза салынган көннән үз көченә керә.

7. Муниципаль хокукый актларны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләрне халыкка җиткерү (рәсми бастырып чыгарудан тыш) гамәлгә ашырыла торган вакытлы матбугат басмаларының, челтәр басмаларының исемлеге «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге тиешле сайтларның домен исемнәрен һәм аларны массакүләм мәгълүмат чаралары буларак теркәү турындагы белешмәләрне күрсәтеп, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башлыгының хокукый актын бастырып чыгару юлы белән бөтен кешегә җиткерелә.».

Чирмешән муниципаль районы
Түбән Кармалка авыл җирлеге
Советының 2024 елның
23 августындагы № 144 карарына
2 нче кушымта

**«Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проектына гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм фикер алышуда гражданнарның катнашуы**
**ТӘРТИБЕ**

1. Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы турында» карар проектына тәкъдимнәр Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлеге Советына түбәндәге адрес буенча кертелә: 423102, Татарстан Респблкасы, Чирмешән районы, Түбән Кармалка авылы, Ленин урамы, 44 нче йорт, яисә (84396) 2-39-47 факсы буенча язма рәвештә яисә кушып бирелә торган үрнәк нигезендә төзәтмәләр таблицасы рәвешендә:

| №/№ п/п | Статья, өлеш, пункт, пунктча | Устав тексты | Уставка төзәтмәләр тексты | Төзәтмә исәпкә алынган проектның тексты | Төзәтмә авторы (Ф.И.Ат.ис., адрес, телефон, эш (уку) урыны) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Тәкъдимнәр эш көннәрендә Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы турында» гы карары басылып чыккан көннән бер ай эчендә 8дән 17 сәгатькә кадәр стендта урнаштыру юлы белән кабул ителә.

2. Халык тыңлауларында чыгыш ясау хокукы белән катнашу өчен гаризалар 423102, ТР, Чирмешән районы, Түбән Кармалка авылы, Ленин ур., 44 нче йорт адресы буенча шәхсән яки почта аша («Устав буенча фикер алышу» яки «Гавами тыңлауларга» тамгасы белән конвертта), шулай ук (84396) 2-39-47 телефоннары буенча эш көннәрендә 8дән 17 сәгатькә кадәр ачык тыңлаулар үткәрү датасына кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча бирелә һәм кабул ителә. Гражданнарның тәкъдимнәре Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлеге Советы хезмәткәрләре тарафыннан теркәлә һәм карау өчен тиешлечә авыл җирлеге Советының эшче комиссиясенә тапшырыла.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Түбән Камалка авыл җирлеге
Советының 2024 елның
23 августындагы № 144 карарына
3 нче кушымта

**«Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлеге Советының карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү**
**ТӘРТИБЕ**

1. Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча ачык тыңлаулар (алга таба - җәмәгать тыңлаулары) Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлеге Уставына, әлеге Тәртипкә ярашлы рәвештә үткәрелә.
2. Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлеге Советына халык тыңлаулары уздырылганчы 7 көннән дә соңга калмыйча язма гаризалар тапшырган Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлеге халкы (алга таба - авыл халкы) үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чыгыш ясау хокукы белән җәмәгать тыңлауларында катнашучылар булып тора.
3. Үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен гариза бирмичә генә авыл җирлеге Советы депутатлары, авыл җирлеге башлыгы, аның урынбасары, авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе, район прокуроры, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының Чирмешән районындагы территориаль дәүләт хакимияте органнары һәм идарәсенең вәкаләтле вәкилләре чыгыш ясый.
4. Халык тыңлауларында чыгыш ясау хокукыннан башка да районның барлык кызыксынган кешеләре булырга мөмкин.
5. Катнашучыларны теркәү ачык тыңлаулар башланырга 1 сәгать кала башлана.
6. Халык алдында тыңлауларда авыл җирлеге башлыгы яки аның кушуы буенча районның җирле үзидарә органының башка вазыйфаи заты рәислек итә.
7. Ачык тыңлаулар рәислек итүченең кереш сүзе белән ачыла, ул катнашучыларга фикер алышына торган мәсьәләнең асылы, тыңлауларны үткәрү тәртибе турында хәбәр итә.
8. Беркетмәне рәсмиләштерү, кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу өчен, рәислек итүче тәкъдиме буенча халык тыңлаулары секретариатына рәислек итүче һәм секретариатның ике әгъзасы сайлана.
9. Төп нотык белән авыл җирлеге Советының җирле үзидарә, Совет Регламенты, хокук тәртибе, экология һәм халыкның куркынычсызлыгы буенча даими комиссиясе карары белән вәкаләтле авыл җирлеге Советы депутаты чыгыш ясый.

10. Чыгыш хокукы белән халык тыңлауларында катнашучылар, гариза бирү вакытына карап, чират тәртибендә үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чакырыла.

11. Халык тыңлауларында катнашучыларның чыгышлары 7 минуттан артык дәвам итәргә тиеш түгел. Рәислек итүче рөхсәте белән чыгыш ясау өчен вакыт озайтылырга мөмкин, әмма 2 минуттан артыкка түгел.

12. Ачык тыңлауларда катнашучылар, чыгыш тәмамланганнан соң, рәислек итүче рөхсәте белән сораулар бирергә хокуклы.

13. Халык тыңлауларында катнашучылар ачык тыңлаулар барышын өзергә һәм үткәрүгә комачауларга хокуклы түгел.

14. Ачык тыңлаулар үткәргәндә тәртипне үтәү ачык тыңлауларда катнашу өчен мәҗбүри шарт булып тора.

15. Халык тыңлауларында катнашучылар үткәрү тәртибен бозган очракта, рәислек итүче аларны утырыш залыннан чыгарып җибәрүне таләп итәргә хокуклы.

16. Чыгышлар тәмамланганнан соң, рәислек итүче ачык тыңлаулар секретариаты җитәкчесенә халык тыңлаулары барышында әйтелгән тәкъдимнәрне ачыклау өчен сүз бирә ала.

17. Халык тыңлауларында катнашучыларның барлык искәрмәләре һәм тәкъдимнәре секретариатка язма рәвештә бирелә һәм ачык тыңлаулар беркетмәсенә теркәлә.

18. Халык тыңлауларының беркетмәсенә рәислек итүче кул куя һәм ул авыл җирлеге Советы материалларында билгеләнгән тәртиптә саклана.

19. Халык тыңлаулары буенча бәяләмә авыл җирлеге Советының җирле үзидарә, Совет регламенты, хокук тәртибе, экология һәм халыкның куркынычсызлыгы буенча даими комиссиясе белән әзерләнә.

20. Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре стендларда урнаштырылу юлы белән игълан ителергә тиеш.

21. Халык тыңлауларын үткәрүне оештыру һәм матди-техник яктан тәэмин итү авыл җирлеге Советы аппараты һәм авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан җирле бюджет хисабына башкарыла.